РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ИШТУГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район, п.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, 11
тел. (84362) 42-0-37

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШТУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы, Иштуган т.ю.р.б., Үзәк урам, 11 йорт
тел. (84362) 42-0-37

e-mail: Isht.sab@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

25.04.2025 ел №10

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының 30.04.2018 елгы №12 "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы"гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елгы №182 «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр органнары, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакындагы 14.04.2025 елгы №228 карары нигезендә, Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 30.04.2018 елгы №12 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::
   1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   «2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 15 389 сум күләмендә расларга.»;
   1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында"гы 30.04.2018 елгы №12 карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   2.1. 2.3 пунктында. «1,072 акчалата бүләкләү түләнә» сүзләрен «1,29 акчалата бүләкләү күләмендә»сүзләренә алмаштырырга.;
   2.2. 3.5.4 нче пунктның икенче җөмләсендә. «41 процент» сүзләрен «58 процент»

сүзләренә алмаштырырга»;

2.3. 7.1 пунктының 5 подпунктында. «18 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга»;

2.4. 6.1 пунктының 2 подпунктында. «4,65 айлык акчалата бүләкләү» сүзләрен «12,86 айлык акчалата бүләкләү» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 01.05.2025 елдан гамәлгә керешкән яңа штат расписаниеләрен расларга.
4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.
5. Әлеге карар 01.05.2025 елдан үз көченә керә.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ishtugan адресы буенча урнаштырырга

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Д.М.Гайнутдинов

Кушымта №1
Саба муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге Советы
25.04.2025 елгы №10 карары

Саба муниципаль районы Иштан авыл җирлеге башлыгы, депутатлары, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларның акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 20091 |
| Депутатлар | 15389 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 15389 |